| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» 03 2024 ел № 104

Торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен куллану турында

Татарстан Республикасы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законын һәм Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы Эксперт-консультация советының 2024 елның 23 гыйнварындагы 13 номерлы хаты һәм торак комиссиясенең 2024 елның 9 февралендәге 2 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү өчен торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен 27636 сум күләмендә кулланырга.

2. Балтач район башкарма комитетының «Торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен куллану турында» 2023 елның 30 мартындагы 126 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов